ГЛАВА БОЛЬШЕБИТАМАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422725, Республика Татарстан Высокогорский район,
с. Большой Битаман, ул Московская, 2В

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ БИТАМАН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
422725, Татарстан Республикасы Биектау районы,
Олы Битаман авылы, Мәскәү ур , 2В

Тел./факс: +7(84365) 62-8-47, e-mail: Bbit.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**26 март 2024 е** **№2**

**Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Олы Битаман, Кече Битаман, Бикнарат, Ювас авылларында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Уставының 22 статьясына ярашлы рәвештә

КАРАР БИРӘМ:

1. Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Олы Битаман авылында үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 07.04.2024 елга билгеләргә. Үткәрү вакыты 10 сәгать 00 минутта. Утырыш урыны: Олы Битаман авылы, Мәскәү урамы, 2В йорт адресы буенча Олы Битаман мәдәният йорты.

1.1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Олы Битаман авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 12 декабрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертүгә ризамы: «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Олы Битаман торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы,:

1) «зират коймасы өчен материаллар сатып алу
2) зиратка койма кору
3) вак таш сатып алу
4) чүплекне бетерү
5) генератор сатып алу
6) юлларны кышын һәм җәен төзекләндереп тору (тракторчыга хезмәт хакы, ЯММ сатып алу)

7) урам яктырту җайланмасы»

2023 елның 12 декабрендәге 4 номерлы карарда күрсәтелгән эш төрләрен өлешендә түбәндәге эшләр белән үзгәртергә:

«- ремонт, коймалар төзү, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (зират коймасы төзү өчен материаллар сатып алу);

- ремонт, коймалар төзү, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (зиратның коймасын төзү);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (вак таш сатып алу)

- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (чүплекне бетерү);

- урам яктырту җайланмасы (генератор сатып алу)

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлларны кышкы һәм җәйге чопрда төзекләндереп тоту (тракторчының хезмәт хакы, ягулык-майлау материаллары сатып алу));

- урамнарны яктырту»

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Кече Битаман авылында үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 07.04.2024 елга билгеләргә. Үткәрү вакыты 13 сәгать 00 минутта. Утырыш урыны: Кече Битаман авылы, Нагорная урамы, 2В йорт адресы буенча Кече Битаман клубы.

2.1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Кече Битаман авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 11 декабрендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертүгә ризамы: «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Кече Битаман торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1) «вак таш сатып алу
2) урам яктырту җайланмасы
3) чүплекне бетерү
4) агачлар кисү
5) юлларны кышын һәм җәен төзекләндереп тору (трасторчыга хезмәт хакы, ЯММ сатып алу)
6) Кече Битаман авылында юлларга вак таш җәю»
7) 2023 елның 11 декабрендәге 3 номерлы карарда күрсәтелгән эш төрләрен өлешендә түбәндәге эшләр белән үзгәртергә:

«- урамнарны яктырту;

каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (чүплекне бетерү);

торак пункты төзекләндерү (агачларны кисү);

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлларны кышкы һәм җәйге чопрда төзекләндереп тоту (тракторчының хезмәт хакы, ягулык-майлау материаллары сатып алу));):

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, төзекләндереп тоту (Кече Битаман авылы урамнарына вак таш түшәү);»

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Бикнарат авылында үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 07.04.2024 елга билгеләргә. Үткәрү вакыты 15 сәгать 00 минутта. Утырыш урыны: Бикнарат авылы, Татарстан урамы, 2А йорт адресы буенча Бикнарат мәчете

3.1 Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

««Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Бикнарат авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 11 декабрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертүгә ризамы: «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Бикнарат торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

«вак таш сатып алу

2) янгынга каршы гидрант сатып алу һәм урнаштыру

3) урам яктырту җайланмасы

4) күперне ремонтлау

5) чүплекне бетерү

6)агачлар кисү

7) юлларны кышын һәм җәен төзекләндереп тору (трасторчыга хезмәт хакы, ЯММ сатып алу)»

2023 елның 11 декабрендәге 2 номерлы карарда күрсәтелгән эш төрләрен өлешендә түбәндәге эшләр белән үзгәртергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, төзекләндереп тоту (вак таш сатып алу);

- янгынга каршы беренчел куркынычсызлыклык чараларын булдыру (янгынга каршы гидрант сатып алу һәм урнаштыру);

- урамнарны яктырту (урманрага яктырткычлар кую);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өстендәге үтүләрне ремонтлау (күперне ремонтлау);

- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (чүплекне бетерү);

- торак пункты төзекләндерү (агачларны кисү)»

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Ювас авылында үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын

07.04.2024 елга билгеләргә. Үткәрү вакыты 17 сәгать 00 минутта. Утырыш урыны: Ювас авылы, Центральная урамы, 14А йорт адресы буенча Ювас ФАПы янында.

4.1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Ювас авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 11 декабрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертүгә ризамы: «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Ювас торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы

«1) вак таш сатып алу

2) янгынга каршы беренчел куркынычсызлыклык чараларын булдыру (янгынга каршы гидрант сатып алу һәм урнаштыру);

3) урам яктырту җайланмасы ;

4) чүплекне бетерү

2023 елның 11 декабрендәге 1 номерлы карарда күрсәтелгән эш төрләрен өлешендә түбәндәге эшләр белән үзгәртергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, төзекләндереп тоту (вак таш сатып алу);

- обеспечение первичных мер пожарной безопасности (приобретение и установка пожарного выхода);

- урам яктырту җайланмасы (урамнарны яктырту);

- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (чүплекне бетерү);»

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының http://vysokaya-gora.tatarstan.ru адресы буенча рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча республиканың рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)

6. Әлеге кара халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы: Закиров Ф.Ю.